Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

6 май 2015 ел №470

Биналар һәм корылмаларга
тикшерү үткәрү тәртибе турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары" турында 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән № 131 Федераль Закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына яраклы рәвештә, Әлмәт муниципаль районы прокуратурасының 2015 елның 9 апрелендәге № 554 нче күрсәтмәсен караганнан соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы карар бирә:

1. Биналар һәм корылмаларның техник торышын, техник, конструктив һәм башка таләпләрен, куркынычсызлык һәм ышанычлылык характеристикаларын бәяләү максатыннан, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре буенча тикшерү үткәрү тәртибе турында нигезләмәне расларга.(Кушымта).

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына йөкләргә:

- әлеге карарны үтәгәндә вәкаләтле дәүләт контроле органнарының бәйләнешен тәэмин итәргә;
- әлеге карарны тормышка ашыру өчен муниципаль хокукый актлар кабул итәргә;

3.Район Советы аппараты юридик бүлегенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар югарыда күрсәтелгән рәсми чыганакларда бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, торак–коммуналь хуҗалык, муниципаль милек (А.И.Верия), социаль мәсьәләләр буенча даими комиссияләренә йөкләргә (Р.Г.Азизов).

Муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Н.М. Хәйдәрова

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2015 елның 6 маендагы № 470
карарына кушымта

Биналар һәм корылмаларның техник торышын, техник, конструктив һәм башка таләпләрен, куркынычсызлык һәм ышанычлылык характеристикаларын бәяләү максатыннан, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре буенча тикшерү үткәрү тәртибе турында
нигезләмә

## 1.Гомуми нигезләмә

1.1.Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары” турындагы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән № 131 Федераль Закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына яраклы рәвештә биналар һәм корылмаларның техник торышын, техник, конструктив һәм башка таләпләрен, куркынычсызлык һәм ышанычлылык характеристикаларын бәяләү максатыннан, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре буенча тикшерү үткәрү тәртибе турында.

1.2.Нигезләмә биналар һәм корылмаларның техник торышын, техник, конструктив һәм башка таләпләрен, куркынычсызлык һәм ышанычлылык характеристикаларын бәяләү максатыннан, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре буенча тикшерү үткәрү тәртибен регламентлаштыра.

1.3.Әлеге нигезләмә Федераль Закон нигезендә биналар һәм корылмалар дәүләт контролендә булмаган очракта биналар һәм корылмаларны тикшерү вакытында кулланыла.

## 2. Биналар һәм корылмаларны тикшерүне оештыру

2.1.Биналар һәм корылмаларны тикшерү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексында каралганча, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан үтәлә.

2.2.Тикшерү бина һәм корылмаларны эксплуатацияләү вакытында Россия Федерациясе Законнарында каралган таләпләр үтәлмәү хакында физик яки юридик затлар тарафыннан гариза кергәндә, авария очраклары булганда яки бинаның ишелү куркынычы булганда үткәрелә.

2.3.Бинаны һәм корылмаларны тикшерү предметы булып әлеге объектларның техник торышын, техник, конструктив һәм башка таләпләрен, куркынычсызлык һәм ышанычлылык характеристикаларын чагылдырган бәяләү тора.

2.4.Биналар һәм корылмаларны тикшерү урыннарда оештырылган комиссия тарафыннан уздырыла.

2.5.Комиссия составы, аның эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты хокукый акты белән раслана.

2.6.Әгәр дә биналар һәм корылмаларны тикшерү өчен махсус белем таләп ителә икән, аны үткәрүгә комиссия аерым белгечләр, экспертлар яки башка дәүләт органнарын җәлеп итә.

2.7.Гариза язучы яки милек хуҗасына, законлы рәвештә, тикшерү булганчыга кадәр 3 эш көне алдан, почта аша яки башка юл белән бина һәм корылмада уздырылачак тикшерү хакында хәбәр ителә.

Бина яки корылмада авария очрагы турында гариза кергәндә, бинаны эксплуатацияләү өчен җаваплы затка, вәкаләтле орган тарафыннан бина яки корылмада тикшерү уздырылу турында кичекмәстән хәбәр ителә.

2.8.Бина, корылмаларны тикшерү вакытында үткәрелә:

– төзелеш конструкцияләренең, инженер–техник тәэмин ителеш, инженер–техник тәэмин ителеш элементларының төзеклеген тикшерү;

– бинаны, корылмаларны эксплуатацияләү барышында узган тикшерүләр журналын карау;

–бина, корылмаларны тикшерү вакытында вәкаләтле органнар тарафыннан ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү, ремонт ясау хакындагы мәгълүматны карау;

–бинаны һәм корылмаларның техник торышын, техник, конструктив һәм башка таләпләрен, куркынычсызлык һәм ышанычлылык характеристикаларын ачыкларга юнәлдерелгән башка чаралар;

2.9.Биналар, корылмаларны тикшерү гариза язылганнан соң 20 көн эчендә үткәрелергә тиеш, әгәр дә милек хуҗасыннан яки аны файдаланучыдан авария очрагы турында гариза кергәндә әлеге вакыт 24 сәгатьтән артмаска тиеш.

2.10.Бина, корылмаларга тикшерү уздырылганнан соң бәяләмә бирелә. Әлеге документка бинаны, корылмаларны тикшерүнең техник диагностикасы, тикшерү барышында тутырылган башка төрле документлар теркәлә.

2.11.Тикшерү барышында бина, корылмаларның техник торышын, техник, конструктив һәм башка таләпләрен, куркынычсызлык һәм ышанычлылык характеристикалары, проект документациясе таләпләре буенча җитешсезлекләр ачыклана икән, аларны бетерү чаралары турында рекомендация языла.

2.12.Бина, корылмаларны тикшерү бәяләмәсенең күчермәсе бинаны эксплуатацияләү өчен җаваплы затларга аны раслаганчы өч көн алдан, бинаны һәм корылмаларның техник торышын авария хәлендә булып куркыныч тудырганда, бинаны карау көнендә үк бирелә.

2.13.Бина, корылмаларның техник торышы, техник, конструктив һәм башка таләпләре бозылганлыгы ачыкланган очракта, вәкаләтле орган әлеге сорауны хәл итәргә тиешле затка өч көн эчендә хәбәр бирергә тиеш.

2.14.Бина, корылмалар тикшерелгәннән соң мәгълүматлар вәкаләтле орган алып бара торган махсус журналга теркәлә.

2.15.Федераль Закон нигезендә эшләүче дәүләт контроле тарафыннан тикшерелгән очракта, бина, корылмаларда тикшерү үткәрелми.

Бу очракта Россия Федерациясе Законы таләп иткәнчә, бина,корылмаларның техник торышы, техник, конструктив һәм башка таләпләре бозылганлыгы ачыкланган очракта, таләпләр күрсәтелгән документ 7 көн эчендә тиешле органнарга җибәрелә.

Гариза язучыга бина, корылмаларны карау үткәрелмәү, әлеге эш белән Федераль Закон нигезендә эшләүче тикшерүче орган шөгыльләнүе хакында мәгълүмат,аларга адресланган гариза теркәлү үткәннән соң 7 көн эчендә тапшырыла.

## 3. Нигезләмәнең үтәлешен контрольдә тоту

3.1.Нигезләмәнең үтәлешен контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

3.2.Нигезләмәнең үтәлешен контрольдә тоту – вәкаләтле органның бина, корылмаларны тикшерү эшендә катнашучы барлык белгечләрнең эшчәнлеген координацияләү аша тормышка ашырыла.

Муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Н.М.Хәйдәрова